РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй
авылы, Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» сентябрь 2017 ел. № 13

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә таләпләрне раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә карата таләпләрне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.М. Вәлиева

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2017 елның 04 сентябрендәге 13 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә таләпләр**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлары нигезендә:

- Әсәй авыл җирлегендә алдан фаразлана торган һәм җаваплы бюджет сәясәтен үткәрү;
- җирлекнең тотрыклы икътисадый үсеше һәм макроикътисадый тотрыклылыгы, Әсәй авыл җирлеге бюджетының балanслылыгы һәм тотрыклылыгы өчен нигез шартлар тудыру (алга таба-җирлек бюджеты);
- бюджет планлаштыруын тәэмин итү һәм бюджет мөмкинлекләре нигезендә җирлекне социаль-икътисадый үстерүгә юнәлдерелгән муниципаль программалар, чаралар, инвестиция һәм башка проектлар кабул итү;
-гражданнарның сыйфатлы муниципаль хезмәтләргә ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлы белән җирлек халкының тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү максатларында районның социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы программасын үтәүне тәэмин итү.

1.2. Әлеге тәртип раслау процедурасын, гамәлдә булу чорын, шулай ук озак сроклы чорга җирлекнең бюджет фаразының составына һәм эчтәлегенә таләпләрне билгели.

1.3. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчә кулланыла - озак сроклы чорга бюджет фаразы - җирле бюджетның төп характеристикалары фаразын, аларның гамәлдә булу чорына муниципаль программаларны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләрен, җирле бюджетны характерлый торган, шулай ук озак сроклы чорга бюджет сәясәтен формалаштыруга төп алымнарны үз эченә алган башка күрсәткечләрне үз эченә алган документ (алга таба - Документ).

## II. Эшләү турында карар кабул итү

2.1. Авыл җирлеген озак сроклы бюджет планлаштыру, әгәр авыл җирлеге Советы аны төзү турында карарны Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләренә туры китереп кабул иткән булса, озак сроклы чорга бюджет фаразын формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

## III. Структурага (составына һәм эчтәлегенә)таләпләр

3.1. Документ җирлекнең социаль-икътисадый үсеше нигезләмәләреннән чыгып эшләнә.

3.2. Озак сроклы бюджет фаразы түбәндәге өлешләрдән тора:

- җирле бюджетның төп характеристикаларын фаразлау;
- муниципаль программаларны аларның гамәлдә булу чорына финанс белән тәэмин итү күрсәткечләре;
- бюджет сәясәтен формалаштыруда төп алымнар;

- җирле бюджетны характерлый торган башка күрсәткечләр.

IV. Үзгәрешләр кертү тәртибе

4.1. Документ җирлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразының тиешле чорга үзгәрүен һәм тиешле бюджет турында кабул ителгән карарны исәпкә алып, аның гамәлдә булу чорын озайтмыйча гына үзгәртелергә мөмкин.

4.2. Үзгәрешләр проекты белән бергә тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең бюджет фаразына һәм аның максатчан күрсәткечләренә йогынтысы, кабул ителә торган карарларның нәтиҗәлелеген нигезләү, тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең финанс-икътисадый нигезләнүе тасвирланган аңлатма язуы әзерләнә.

V. Документны раслау

5.1. Документ проекты яисә документка үзгәрешләр проекты (муниципаль программаларны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш) авыл җирлеге советына авыл җирлеге бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта тапшырыла.

5.2. Документ яисә аңа үзгәрешләр авыл җирлеге бюджеты турында карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән алып 2 айдан да артмаган вакытта авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

VI. Документның гамәлдә булу чоры

6.1. Документ җирлекнең тиешле чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә һәр өч ел саен алты һәм аннан да күбрәк елга әзерләнә.